КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 март г.Казань № 211

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2013 ел, 31 декабрь, 1097 нче карары белән (Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2014 ел, 10 июнь, 393 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 955 нче; 2015 ел, 3 октябрь, 739 нчы; 2017 ел, 27 октябрь, 813 нче; 2017 ел, 22 декабрь, 1021 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1269 нчы; 2019 ел, 1 ноябрь, 994 нче; 2020 ел, 15 октябрь, 930 нчы; 2021 ел, 30 декабрь, 1348 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшчеләр вазыйфалары буенча һөнәри эшчәнлек
гамәлгә ашыручы хезмәткәрләрнең тариф ставкалары

5 нче таблица

| Тариф ставка-лары төркем-нәре | I | II | III | IV | V | VI | VII | VIII | IX |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Тариф-лар ставка-сы күләме, сум | 13 617 | 13 848 | 14 158 | 14 473 | 15 223 | 16 060 | 16 894 | 17 815 | 18 832 – 20 878»; |

7 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7 нче таблица

| Т/с | Су астына төшү тирәнлеге (метрда) | Су астында 1 сәгать булган өчен түләү күләме (хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән процентта) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | 6 га кадәр | 2,5 |
| 2 | 6 дан 12 гә кадәр | 3,5 |
| 3 | 12 дән 20 гә кадәр | 4 |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 4 | 20 дән 30 га кадәр | 5 |
| 5 | 30 дан 40 ка кадәр | 6 |
| 6 | 40 тан 50 гә кадәр | 6,5 |
| 7 | 50 дән 60 ка кадәр (60 ны кертеп) | 7,5 |
| 8 | Су астында турыдан-туры грунтта яки объектта эшләгән вакыт өчен, шулай ук водолаз су асты аппаратының водолаз гөмбәзендә яки водолаз бүлегендә бик зур басым астында булган өчен: | |
| | 60 тан 70 кә кадәр | 40 |
| | 70 тән 80 гә кадәр | 50 |
| | 80 нән 90 га кадәр | 70 |
| | 90 нан 100 гә кадәр (100 не кертеп) | 85 |
| 9 | Шуннан соңгы һәр 10 тапкыр су астына төшү өчен сәгать исәбеннән түләү арттырыла | |
| | 100 дән 150 гә кадәр | 2,5 |
| | 150 дән артык | 3 |
| 10 | Барокамерада билгеләп куелган эш басымы астында булган вакыт өчен | |
| | 60 ка кадәр | 2,5 |
| | 60 тан артык | 3,5»; |

18 пунктта:

5 пунктчаның беренче абзацында «5 процент» сүзләрен «2,5 процент» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктчада:

беренче абзацта «хезмәт өчен түләүнең 5 минималь күләменә тигез» сүзләрен «хезмәт өчен түләүнең 2,5 минималь күләменә тигез» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «хезмәт өчен түләүнең 5 минималь күләме» һәм «хезмәт өчен түләүнең 25 минималь күләме» сүзләрен шул ук эзлеклелектә «хезмәт өчен түләүнең 2,5 минималь күләме» һәм «хезмәткә түләүнең 12,5 минималь күләме» сүзләренә алмаштырырга;

20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20. Дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүматлар белән эшләгән, аларны яшерен иткән һәм яшеренлеген бетергән өчен, шулай ук законнар нигезендә шифрлар белән эшләгән өчен өстәмәләр.

Дәүләт сере белән эшләргә даими нигездә рөхсәт ителгән хезмәткәрләрнең окладына ай саен бирелә торган процентлы өстәмә бу хезмәткәрләрнең законнар нигезендә документлар белән раслана торган рөхсәте булган мәгълүматлар серлелеге дәрәҗәсенә карап түләнә:

«аеруча мөһим» – 12,2 – 18,3 процент;

«бик яшерен» – 7,4 – 12,2 процент;

«яшерен» – тикшерү чараларын үткәреп, рөхсәт итүне рәсмиләштергәндә – 2,5 – 3,7 процент, тикшерү чараларын үткәрмичә – 1,3 – 2,5 процент.

Ай саен бирелә торган процентлы өстәмә күләмен билгеләгәндә, әлеге хезмәткәрләрнең эшләргә рөхсәте булган мәгълүматларның күләме, шулай ук бу мәгълүматларны яшерен итү актуальлеге саклана торган срок озынлыгы исәпкә алына.

Дәүләт серен саклау буенча структур бүлекчәләр хезмәткәрләренә әлеге структур бүлекчәләрдә эш стажы өчен окладка ай саен бирелә торган процентлы өстәмә түләнә:

1 елдан 5 елга кадәр – 2,5 процент;

5 елдан 10 елга кадәр – 3,7 процент;

10 елдан һәм аннан күбрәк – 4,9 процент.»;

V бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V бүлек. Хезмәт өчен түләү фондын формалаштыру тәртибе

36. Учреждениеләрнең хезмәт өчен түләү фонды, хезмәткәрләрнең штат санына исәпләп, хезмәт өчен түләүгә бүлеп бирелә торган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә формалаштырыла.

37. Хезмәт өчен түләүнең еллык фонды түбәндәгеләрне түләү өчен җибәрелә торган акча күләменнән чыгып формалаштырыла:

1) Учреждениеләр җитәкчеләренең окладларын (вазыйфаи окладларын, тариф ставкаларын), шул исәптән вазыйфаи окладларын;

2) компенсация характерындагы;

3) стимуллаштыру характерындагы.

38. Хезмәт өчен түләү фонды түбәндәге очракларда яңадан исәпләп чыгарылырга һәм аңа төзәтмәләр кертелергә тиеш:

окладларны арттырганда (индексацияләгәндә);

штатлар (штат расписаниеләре, штат исемлекләре) үзгәргәндә;

хезмәт өчен түләү шартларына җитди үзгәрешләр кертелгәндә;

бюджет акчасы белән баш эш итүче тарафыннан бер тапкыр бирелә торган стимуллау характерындагы түләүләр өчен өстәмә бюджет йөкләмәләре лимитларын бүлеп бирү турында карар кабул ителгәндә;

бюджет акчасы белән баш эш итүче тарафыннан компенсация характерындагы түләүләр өчен өстәмә бюджет йөкләмәләре лимитларын бүлеп бирү турында карар кабул ителгәндә;

бюджет акчасы белән баш эш итүче тарафыннан хезмәт өчен түләү фондына арттыру коэффициентын билгеләгәндә.».

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин